СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2021 с. Сарманово № 38

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы советының 2011 елның 23 ноябрендәге 47 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 4 пункты нигезендә Сарман муниципаль районы советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы советының 2011 елның 23 ноябрендәге 47 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Контроль-хисап палатасы рәисе вәкаләтләре срогы биш ел тәшкил итә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет Рәисе Ф. М. Хөснуллин